Шәрипов, Х. Татар бизәкләрендә - ата-бабалардан калган көч / Х. Шәрипов; [әңгәмәдәш] С. Гарипова // Шәһри Чаллы. – 2023. – №26 (14 апрель). – С. 2

Хәмзә Шәрипов:

# «Татар бизәкләрендә – ата-бабалардан калган көч»

Сәрия **Гарипова**



**Чаллы рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Хәмзә Шәрипов эскизлары буенча яулыклар җитештерә башлаганнар. Бу яңалыкны ишетү белән авторның үзе белән очрашырга булдык. Ул «Шәһри Чаллы» редакциясенә килеп, ВКонтакте төркемебездә әңгәмә корырга ризалашты. Үзе белән күз явын алырлык матур, нәфис тукымадан эшләнгән яулыкларын да алып килде.**

**– Хәмзә абый, милли темага игътибар итүегез кайчан башланды?**

– Мин этноавангард стилендә иҗат итүче рәссам. Ягъни милләтне сәнгать аша танытам. Санкт-Петербургның сәнгать-сәнәгать академиясен 1987 елда тәмамлап, Татарстанга кайттым. Тумышым белән мин Пермь якларыннан. Бөтен иҗатымны татарның матурлыкны аңлавын, үз сәнгате булуын исбатлауга багышладым. Күбесенчә картиналар ясадым. Батик техникасында Чаллыдагы 20ләп объектны бизәдем. Анда күбрәк татар орнаментын күрсәтергә тырыштым.

**– Бизәкләрнең татарныкы икәнлеге нәрсәдән күренә?**

– Кешедә генетик хәтер дигән әйбер бар. Мин Алтайдагы тауларда кыя ташка ясалган рәсемнәрне өйрәндем. Петроглиф дип аталган мондый рәсемнәр Италия, Австралиядә дә бар. Тик нәкъ менә боларына карау белән аларның безнеке икәнен аңлыйсың. Ничекме? Анда ритм бар, линияләр, стилизация. Кайберәүләр абстракцияне 20нче гасырда уйлап чыгарылган дип уйлый. Юк, ул борынгыдан килә, табигатьтә дә бар. Әйтик, күбәләк канатындагы бизәк – ул абстракция. Андагы линияләр, таплар, нокталар үзенә бер ритмны тәшкил итә.

Алтайдагы Пазырик курганнарында (безнең эрага кадәр 5-3нче гасырга караган төрбәләр) киездән мозаика стилендә ясалган эшләнмәләр табылды. Алар Эрмитажда саклана. Кызганычка каршы, алар төрки халыкларның сәнгате дип күрсәтелми. Тик андагы борынгы орнаментлар татар читекләрендә кабатлана.

**– Димәк, Сезнең яулыклардагы бизәкләр уникаль?**

– Орнаментларны үзең уйлап чыгару катлаулырак, шунысы белән кыйммәтлерәк тә. Татар авылларында, минем туган ягым Пермь өлкәсе Барда районында да тәрәзә наличникларын электән бик матур, кабатланмас итеп бизәгәннәр. Бүген аларның югала баруы бик аяныч. Өлгеләрдән хәтта музей ачарга булыр иде. Мин андый тәкъдим белән җитәкчелеккә дә чыктым, тик, кызганыч, колак салучы булмады.

**– Яулыкларны каян алырга була?**

– Казанның татар киемнәрен сатучы бер интернет-кибете белән эшлим. Минем эскизлар, башка рәссамнарның эскизлары буенча да яулыклар, шопер дип аталган тукыма сумкалар, футболкалар җитештерәләр. Бәяләргә килгәндә, размерына карап, 500дән 1 мең сумга кадәр.

**– Сезнең бизәкләрнең үзенчәлеге нәрсәдә?**

– Беренчедән, аларда төрки рух бар. Икенчедән, бу – абстракция. Рәссам иҗат итә, ә аның эшен караучы ул бизәкләрдә күргән образ, тоемлаган хисләр аша шул иҗатны дәвам итә. Аннары алар безгә борынгы ата-бабаларыбыздан килгән рухи көчне, энергияне тоярга ярдәм итә. Безгә кадәр яшәгән буыннар турында мәгълүмат югалмый, геннарыбыз аша күчә.

**– Бүген Сез нинди эш белән мәшгуль?**

– Күңелем сызлана, чөнки татар халкы рәсем сәнгатеннән коточкыч ерак. Европа илләре белән чагыштырырлык түгел. Ә бит көчле рәссамнарыбыз бар. Алар мескен хәлдә. Бакый Урманчега бәләкәй генә музей ясап куйдылар. Ул бит шундый даһи, бөтен дөньяга танытырлык рәссам.

Мин хәзер сәнгать, каллиграфия буенча лекцияләр укыйм. Сәнгатьнең тормышның мәгънәсен күрергә, матурлыкның нәрсә икәнен аңларга, яхшыны яманнан аерырга ярдәм итүе турында сөйлим. Матурлыкны күрә белгән кеше депрессиягә бирелми.